**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

30.10.2020 г. — № 399

Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының 27.05.2009 ел, № 161 карары белән расланган,Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният һәм мәгариф бүлекләре структур бүлекчәсе булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында нигезләмәгә һәм Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 05.08.2020 елдагы № 655 Карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Әтнә район Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» (23.09.2020 елдагы № 9 үзгәрешләр белән) 16.04.2018 елдагы № 102 карарына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният һәм мәгариф бүлекләре структур бүлекчәсе булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү

шартлары һәм оештыру турында нигезләмәгә һәм Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләү шартлары турындагы, Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының 27.05.2009 елдагы № 161 карары белән расланган, нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Ф.И.Гыймадиевка йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов

Кушымта
Әтнә район башкарма комитетының
30.10.2020 елдагы № 399 карарына

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният һәм мәгариф бүлекләре структур бүлекчәсе булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турындагы нигезләмәгә һәм Әтнә муниципаль районы башкарма комитетлары баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр, Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының 27.05.2009 ел, № 161 карары белән расланган

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният һәм мәгариф бүлекләре структур бүлекчәсе булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәнең 3 нче пунктындагы таблицасын (карарның 1 нче кушымтасы) яңа редакциядә бәян итәргә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| | Башкарма комитетның (башка җирле үзидарә органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлеге) |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш хисапчы) | 22145 |
| Бүлек башлыгы | 18231 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 15 759 |
| Хисапчы | 14 420 |

2. Муниципаль берәмлекләрнең баш хисапчылары һәм хисапчылары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында нигезләмәнең 3 пунктындагы таблицасын (карарның 2 нче кушымтасы) яңа редакциядә бәян итәргә:

| Вазифа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | 16171 рублей | 17 510 рублей |
| Бухгалтер | - | 14 935 рублей |